**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**«ИСКЕ АБДУЛ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»**
**МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

«19» май 2022 ел                                                                 № 17/3

**Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Иске Абдул авыл җирлеге» муниципаль бемлеге Советының 2021 елның 10 декабрендәге 13/4 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иске Абдул авыл җирлегендә инициатив проектларны тәкъдим итү, кертү, фикер алышу һәм карау тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 26.1 статьясы, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Уставы нигезендә Иске Абдул авыл җирлеге Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Иске Абдул авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2021 елның 10 декабрендәге 13/4 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иске Абдул авыл җирлегендә инициатив проектларны тәкъдим итү, кертү, фикер алышу һәм карау тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 6 статьяның 4 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«Җыелыш үткәрелә:

көндезге формада – көн тәртибендәге мәсьәләләр буенча фикер алышу һәм тавышка куелган мәсьәләләр буенча карарлар кабул итү өчен халыкның уртак катнашуы формасында».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Тукай муниципаль районының мәгълүмат сайтында (https://tukay.tatarstan.ru/) урнаштырырга.

3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны законлылык, милли мәсьәләләр һәм халык куркынычсызлыгы буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы,
Совет рәисе                                                                 Р.Х.Сафина